КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 13 июль г.Казань № 580

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ведомствоара эшче төркем төзү турында» 2016 ел, 14 июль, 477 нче карары белән расланган гражданнарның аерым категорияләрен дарулар белән тәэмин итү өлешендә социаль хезмәтләр җыелмасы белән тәэмин итүгә юнәлдерелгән чараларны оештыру һәм үткәрү буенча ведомствоара эшче төркем составына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ведомствоара эшче төркем төзү турында» 2016 ел, 14 июль, 477 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 19 апрель, 265 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган гражданнарның аерым категорияләрен дарулар белән тәэмин итү өлешендә социаль хезмәтләр җыелмасы белән тәэмин итүгә юнәлдерелгән чараларны оештыру һәм үткәрү буенча ведомствоара эшче төркем составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

эшче төркем составыннан Э.Ф.Әхмәтованы чыгарырга;

эшче төркем составына түбәндәгеләрне кертергә:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре буенча идарәсенә караган сәламәтлек саклау мәсьәләләре секторының баш киңәшчесе Светлана Хатыйп кызы Галиеваны;

«Татарстан Республикасы Инвалидлар җәмгыяте» бөтенроссия инвалидлар җәмгыятенең Татарстан республика оешмасы рәисе Рифат Шаһит улы Ганибаевны (килешү буенча);

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Фармация идарәсенә караган дару чаралары әйләнеше өлкәсендә җайга салу бүлеге башлыгы Ирина Юрьевна Ермолаеваны;

Татарстан Республикасы Ветераннар (пенсионерлар) төбәк иҗтимагый оешмасының республика советы рәисе Хәбир Газиз улы Иштирәковны (килешү буенча);

Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе урынбасары Илдар Флүс улы Миргалимовны;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Фармация идарәсе башлыгы Артур Олегович Пологовны.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин